Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XLIII-4**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 26 июне

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминиятләве турында Нигезләмәне раслау хакында

2007 елның 2 мартындагы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 25-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминиятләве турында Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл һәм шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарына эшләрендә әлеге Нигезләмәне куллануны тәкъдим итәргә.

3. Карар рәсми төстә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2019 елның 26 июнендәге
XLIII-4 номерлы карары белән
расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминиятләве турында**
**Нигезләмә**

1.Әлеге Нигезләмә муниципаль хезмәткәрнең сәламәтлегенә зыян килгән очракта муниципаль хезмәткәрләрнең тормышын һәм сәламәтлеген мәҗбүри дәүләт иминиятләве буенча түләүләр очракларын, тәртибен һәм күләмнәрен билгели (алга таба – мәҗбүри дәүләт иминиятләве).

2.Үзидарәлек хезмәткәре вазыйфасына билгеләнгән көннән алып аннан азат ителү көненә тикле муниципаль хезмәттә булуның бөтен чоры дәвамында үзидарәлек хезмәткәренең тормышына һәм саулыгына мәҗбүри дәүләт иминиятләве тиеш.

3.Мәҗбүри дәүләт иминиятләве буенча иминләштерүче булып үзидарәлек хезмәткәре муниципаль хезмәт уза торган җирле үзидарә органнары яки бүтән үзидарәлек органнары тора (алга таба – иминләштерүчеләр (страхователи)).

4. Мәҗбүри дәүләт иминиятләве буенча иминиятчеләр (алга таба – иминиятчеләр (страховщики)) булып мәҗбүри дәүләт иминиятләвен гамәлгә ашыруга лицензияләре булган иминият оешмалары торырга мөмкин.

Иминиятчеләрне сайлап алу Россия Федерациясенең дәүләт һәм муниципаль хаҗәтләр өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы законнарда күздә тотылган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5.Иминият шартнамәсе иминиятче һәм иминләштерүче арасында иминиятләштерелгән зат (файда алучы) файдасына бер календарь еллык срокка тәүлекнең 24 сәгате дәвамында иминият таянычы белән Россия Федерациясе законнарында күздә тотылган тәртиптә төзелә.

Әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән иминият очраклары өчен иминият шартнамәсендә иминләштерүче тарафыннан файда алучылар даирәсе билгеләнә.

Иминият шартнамәсендә иминләштерүче тарафыннан мәҗбүри тәртиптә файда алучылар сыйфатында аталырга тиешле:

иминләштерелгән затның вафат булу көненә аның белән теркәлгән никахта торучы ире (хатыны);

иминләштерелгән затның әти-әнисе (уллыкка алучылары), иминләштерелгән затның әбисе һәм бабасы, әгәр аның әти-әнисе юклыктан алар аны өч елдан ким булмаган вакыт тәрбияләгән һәм караган булсалар;

иминләштерелгән затның үги әтисе һәм үги әнисе, әгәр алар аны биш елдан ким булмаган вакыт тәрбияләгән һәм караган булсалар;

иминләштерелгән затның 18 яшькә җитмәгән яки аннан олырак балалары, әгәр алар 18 яшькә җиткәнче инвалид була калсалар, шулай ук оештыру-хокукый формаларына һәм милек формаларына бәйсез рәвештәге белем бирү оешмаларында укучы балалары укуны тәгалләгәнче, тик 23 яшькә җиткәнче генә;

иминләштерелгән затның опекага алынган балалары.

Иминият шартнамәсендә файда алучылар аның иминләштерүчесе билгеләгән тәртиптә граждан (хезмәткәр) биргән мәгълүмат нигезендә күрсәтеләләр. Иминият шартнамәсендә файда алучылар күрсәтелмәгән булса, файда алучылар булып гражданлык законнарында билгеләнгән тәртиптә иминләштерелгән затның варислары таныла.

6. Муниципаль хезмәткәрне үзидарәлек хезмәте вазыйфасыннан төзелгән иминият шартнамәсенең гамәлдә булу вакыты чыкканчы азат итү үзидарәлек хезмәте вазыйфасыннан азат итү датасыннан күрсәтелгән муниципаль хезмәткәргә карата аның көче тукталуына сәбәп була.

Иминият шартнамәсенең гамәлдә булуы күрсәтелгән нигез буенча үзидарәлек хезмәткәренә карата срогыннан алда туктатылган очракта иминиятче әлеге муниципаль хезмәткәрне иминиятләү белән бәйле түләнгән иминият премиясенең әлеге муниципаль хезмәткәргә карата иминият шартнамәсенең гамәлдә булу срогының калган өлешенә пропорциональ итеп әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында билгеләнгән тәртиптә иминләштерүчегә кире кайтара.

7. Иминият очраклары булып тора:

1) иминләштерелгән затның муниципаль хезмәт узу чорында, шулай ук муниципаль хезмәт узу чорында алынган имгәнү, җәрәхәт һәм чирләү нәтиҗәсендә үзидарәлек хезмәтеннән азат ителгәннән соң бер ел дәвамында үлеме;

2) иминләштерелгән затка муниципаль хезмәт узу чорында, шулай ук муниципаль хезмәт узу чорында алынган имгәнү, җәрәхәт һәм чирләү нәтиҗәсендә үзидарәлек хезмәтеннән азат ителгәннән соң бер ел дәвамында инвалидлык билгеләнү;

3) муниципаль хезмәт узу чорында иминләштерелгән затның имгәнү яки җәрәхәт алуы;

4) иминләштерелгән затның эшкә яллаучы вәкиле инициативасы буенча хезмәт контрактын өзү өчен нигез булып торган авыру алуы белән үзидарәлек хезмәткәрен муниципаль хезмәттә биләгән вазыйфасыннан азат итү һәм сәламәтлеге буенча инвалидлык билгеләү белән бәйләнмәгән медицина бәяләмәсе нигезендә муниципаль хезмәттән җибәрү;

8.Иминләштерелгән затларга (файда алучыларга) түләнә торган иминият суммаларының күләме муниципаль хезмәткәрне тотуның айлык акчалата окладын тәшкил итүче үзидарәлек хезмәткәренең ул биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы нигезендә вазыйфаи окладыннан һәм класслы чин өчен айлык өстәмәдән чыгып тәгаенләнә (алга таба – оклад).

9. Иминият очраклары туганда иминият суммалары түбәндәге күләмнәрдә түләнә:

1) иминләштерелгән зат муниципаль хезмәт узган чорда, шулай ук муниципаль хезмәт узу чорында алынган имгәнү, җәрәхәт һәм чирләү нәтиҗәсендә үзидарәлек хезмәтеннән азат ителгәннән соң бер ел дәвамында вафат булган очракта – 26,25 оклад. Күрсәтелгән иминият суммасы файда алучыларга тигез өлешләрдә түләнә;

2) иминләштерелгән затка инвалидлык муниципаль хезмәт узу чорында, шулай ук муниципаль хезмәт узу чорында алынган имгәнү, җәрәхәт һәм чирләү нәтиҗәсендә үзидарәлек хезмәтеннән азат ителгәннән соң бер ел дәвамында билгеләнгән очракта:

I төркем инвалидка - 17,5 оклад;

II төркем инвалидка - 12,25 оклад;

III төркем инвалидка - 10,5 оклад;

3) муниципаль хезмәт узу чорында иминләштерелгән зат каты имгәнү яки җәрәхәт алган очракта – җиде оклад, җиңел имгәнү яки җәрәхәт алган очракта – 1,75 оклад.

Тиңдәшле иминият суммасы түләнү белән бәйле гарипләнү һәм тән җәрәхәте алуны авыр яки җиңелчәгә кертү имгәнүләрнең (яралану, җәрәхәтләнү, контузияләр) 1998 елның 28 мартындагы “Хәрби хезмәткәрләрнең, хәрби сборларга чакырылган гражданнарның, Россия Федерациясе эчке эшләр, Дәүләт янгынга каршы хезмәт органнарының рядовой һәм башлыклар составы затларының, җинаять-үтәү системасы органнары һәм учреждениеләре хезмәткәрләренең, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре хезмәткәрләренең гомерен һәм сәламәтлеген мәҗбүри дәүләт иминиятләве турында” 52-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә расланган исемлегенә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

4) иминләштерелгән затның эшкә яллаучы вәкиле инициативасы буенча хезмәт контрактын өзү өчен нигез булып торган авыру алуы белән үзидарәлек хезмәткәрен муниципаль хезмәттә биләгән вазыйфасыннан азат итү һәм сәламәтлеге буенча инвалидлык билгеләү белән бәйләнмәгән медицина бәяләмәсе нигезендә муниципаль хезмәттән җибәрелү очрагында – 8,75 оклад.

Әгәр муниципаль хезмәт узу чорында яисә үзидарәлек хезмәте вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел үтмәстән иминләштерелгән затка медик-социаль экспертизаның федераль учреждениесендә яңадан тикшерелгәндә инвалидлык төркеме күтәрелсә, иминият суммасы яңа һәм элекке окладлар аермасына тигез булган сумма күләмендә арттырыла.

Әгәр иминият очрагы белән бәйле рәвештә иминләштерелгән затка иминият суммасы түләнгән булып, иминият очрагы җиткән көннән соң һәм аның белән турыдан-туры бәйлелектә ел дәвамында аның сәламәтлеге начарланса яки үлсә, элекке түләнгән иминият суммасын (суммаларын) чигереп өстәмә иминият түләве бирелә.

Һәрбер иминләштерелгән затка түләнә торган иминият премиясенең күләме иминият шартнамәсе белән тәгаенләнә һәм иминләштерелгән затның иминият шартнмәсе төзелү моментына билгеләнгән окладының 8,75 процентыннан артык була алмый.

10.Мәҗбүри дәүләт иминияте буенча иминият суммасын түләүдән иминиятче азат ителә, әгәр иминият очрагы:

1)иминләштерелгән зат тарафыннан суд тәртибендә иҗтимагый куркыныч дип танылган эш кылу нәтиҗәсендә барлыкка килсә;

2) иминләштерелгән затның суд тарафыннан расланган алкоголь, наркотик кулланып яки токсик исереклек белән турыдан-туры сәбәп булырдай элемтәсе булса;

3)иминләштерелгән затның суд тарафыннан исбатланган явыз ният белән үз сәламәтлегенә зыян салуы яки үз-үзенә кул салуы нәтиҗәсендә булса.

Иминләштерелгән затның үлеме суд тарафыннан исбат ителеп үзенә кул салу нәтиҗәсе булып торган очракта иминиятче иминият суммасын түләүдән азат ителми.

Иминият суммасын түләүне кире кагу турында карар иминиятче тарафыннан кабул ителә һәм иминләштерелгән затка (файда алучыга) һәм иминләштерүчегә язма рәвештә күрсәтелгән кире кагуның сәбәпләрен мәҗбүри дәлилле нигезләү белән иминият суммасын түләүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән срокта хәбәр ителә.

11.Иминият түләүләрен гамәлгә ашыру иминиятче тарафыннан иминләштерелгән затның (файда алучының) гаризасы һәм иминләштерүче тапшырган иминият очрагы җитүен раслаучы документлар нигезендә эшләнә.

Иминият түләвен гамәлгә ашыру, аларны бирү һәм карау тәртибе турында карар кабул итү өчен зарури документлар исемлеге иминият шартнамәсе белән билгеләнә.

Иминият суммаларын түләү иминләштерелгән затларга иминият шартнамәләренең бүтән төрләре буенча тиеш булган суммаларга бәйсез рәвештә эшләнә.

Иминият суммалары иминиятче тарафыннан иминләштерелгән затларга (файда алучыларга) иминият шартнамәсендә тәгаенләнгән ысул белән тигән сумманы сумнарда күчерү юлы белән түләнә.

Иминият суммаларын түләү иминиятче тарафыннан күрсәтелгән түләү турында карар кабул итү өчен кирәкле документларны алган көннән соң 10 көнлек срокта эшләнә.

12.Иминият шартнамәсенең гамәлдә булу срогы дәвамында иминләштерелгән затларның оклад күләмнәре, шулай ук аларның санында үзгәреш булса, күрсәтелгән хәлләр белән бәйле рәвештә иминият взносларының алып җиткерелмәгән яки артык алынган суммалары өстәп түләнергә яки кире кайтарылырга тиеш. Иминият шартнамәсен төзүче якларның килешүе буенча күрсәтелгән суммалар иминият шартнамәсенең гамәлдә булуының чираттагы чорына иминият взнослары күләмен билгеләгәндә исәпкә алынырга мөмкин.

Иминләштерүче тарафыннан иминият взносларын кертүнең кабатлану тәртибе (периодиклыгы) иминият шартнамәсендә тәгаенләнә.

13. Мәҗбүри дәүләт иминиятләвенә чыгымнарны финанслау муниципаль берәмлек бюджеты средстволары исәбенә гамәлгә ашырыла.